
# Фигыль һәм аның нигезе



- Хәерле көн, укучылар,
- Хәерле көн барчагызга
- Телимен чын йөрәктән.
- Башлыйк дуслар дәресне
- Шундый изге ният тән.



# “Сүз төркемнәре ” иле



# Сез нинди сүз төркемнәрен өйрәндегез?

# Сүз төркемнәре

Исем

Сыйфат

Сан

Алмашлык

Рәвеш

Тукай, укый, яшел, алан,
агачлар, кыскан, матур,
аларны,табигать,күңелле,
тиз-тиз,мин,язган, әкият.

**Исем нәрсәне белдерә?**

**Нинди сорауларга җавап бирә?**

**Исемнәр нинди ике төргә бүленә?**

**Исем нәрсә белән төрләнә?**



**1.Нинди сүз төркеме сыйфат дип атала?**

1. Предметның билгесен белдерә
2. Предметның эшен белдерә
3. Предметны белдерә

**2.Сыйфат нинди сорауларга җавап бирә?**

1.Кем? Нәрсә?

2.Нинди? Кайсы?

3.Нишли? Нишләде?

**3.Кайсы юлда сыйфатлар гына язылган?**

1.Яшел, бара, кызыл.

2.Әби, матур, чаба.


3.Биек,зәңгәр,тәмле.

# Алмашлык





**Мин,шушы,кем,һичкем,
әллә нәрсә, барлык,
аныкы,безнеке, үз,
кайдадыр,беркем,
ничәнче,менә,без**



1.Зат алмашлыклары:мин,без

2.Күрсәтү алмашлыклары:шушы, менә

3.Сорау алмашлыклары:кем, ничәнче

4.Юклык алмашлыклары:һичкем, беркем


5.Билгесезлек алмашлыклары:әллә нәрсә, кайдадыр

6.Билгеләү алмашлыклары:барлык, үз

7.Тартым алмашлыклары:аныкы, безнеке



Эшне, хәлне, хәрәкәтне
Без белдереп киләбез.
Эшләүчеләр азмы, күпме
Икәнен дә беләбез.




# Фигыль урманы





**Исәнмесез, балалар,**
**Минем исемем – Шүрәле.**
**Тукай әкиятеннән килдем,**
**Мине яратасызмы әле?**



Әй сылу кыз, **кил** әле, син дә бераз бармакларыңны **селкет.**

Килче, икәү **уйныйк** бераз кети-кети.

Бер дә **шикләнмә**, кызый, син: мин карак-угъры түгел,


Юл да **кисмимен**, шулай да мин бигүк тугъры түгел...

# Фигыльнең нигезе-башлангыч формасы



**Кил ,селкет,уйныйк , кис-мимен –боерык фигыль - тамыр нигез**

**Шик-лән-мә-ясалма нигез**



Кил ,селкет,уйныйк – **барлыкта**

Кисмимен,шикләнмә- **юклыкта**

# Заман белән төрләнеше

**Хәзерге заман- килә, уйный**

**Үткән заман- килде,уйнаган**

**Киләчәк заман- киләчәк, уйнар**

# Зат-сан белән төрләнеше

| | |
|---|---|
| Мин | Без |
| Син | Сез |
| Ул | Алар |

# Татар халкының сөекле шагыйре Габдулла Тукайның туусына быел 130 ел тула.



Эшли, уйлау, сикерә,йоклый, куана,казый, төшенү, йөгерә, утыра, кайгыра,сибә,аңлау,бара, басып тора, дулкынлана.

# Фигыльләрне мәгънә төркемчәләре буенча аерып язарга.

**Эшне белдерә:**

**акыл эшчәнлеген белдерә:**

**хәрәкәтне белдерә:**

**хәл-торышны белдерә:**

**хис-кичерешне белдерә:**

**Эшне белдерә:** эшли, казый,сибә

**акыл эшчәнлеген белдерә:** уйлау, төшенү, аңлау

**хәрәкәтне белдерә:** сикерә, йөгерә, бара

**хәл-торышны белдерә:**йоклый, утыра, басып тора


**хис-кичерешне белдерә**: куана, кайгыра, дулкынлана

Бирелгән фигыльләрне юклыкта әйтергә


# Бар , кил, кайт, яз,  яса, аша.

**Бүгенгэ дәрестә нинди сүз төркеме турында сөйләштек?**

**“Фигыль” урманы бик куе. Адашмассыз дип ышанып калам.**



- фигыль нәрсәне белдерә?
- фигыльләргә нинди сораулар куела?
- фигыльләр ничек төрләнә?
- фигыль нинди заманнарда килә?
- эш яки хәлнең үтәлү-үтәлмәвенә карап, фигыльнең нинди формалары була?



# Фигыль

эшне хәрәкәтне хәлне белдерә

нишли? нишләгән? нишләр?

Заман: хәзерге үткән киләчәк

Барлыкта юклыкта

Зат-сан белән төрләнә

# Өй эше.

1. Фигыльләрне кулланып ,шигырь яки хикәя формасында өзекне дәвам итәргә.

“Ерак Кырлай ягыннан
Хәбәрчебез саескан:
“Шүрәлене саклагыз”,- дип,
Телеграмма суккан....”

2. Фигыльләрне кулланып, “Минем гаиләм” темасына хикәя язарга.

**Зәңгәр -дәрес ошады, аңладым.**

**Сары-материалны аңладым, шулай да соравым бар.**

**Ал-дәрес темасы авыр иде, аңлап житкермәдем.**

**Рәхмәт сезгә, балалар, Г. Тукайның әсәрләрен яхшы беләсез икән. Димәк, сез шагыйрь абыегызның яңа шәкертләре. Аның шигырьләрен, әкиятләрен укып, яраткан җырларын җырлап, тормыш сабагы аласыз. Сез – яшь тукайчылар. Изге туган телебезгә, газиз татар теленә Тукай кебек тугры булып үсегез.**

Урман хуҗасы Шүрәле актив булганыгыз өчен сезгә үзенең бүләкләрен калдыра.

Рәхмәт. Сау булыгыз!